УПРАВЛЕНИЕ ПО НАДЗОРУ ЗА ТЕХНИЧЕСКИМ СОСТОЯНИЕМ САМОХОДНЫХ МАШИН И ДРУГИХ ВИДОВ ТЕХНИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАЛАР ҺӘМ БАШКА ТӨР ТЕХНИКАНЫҢ ТЕХНИК ТОРЫШЫНА КҮЗӘТЧЕЛЕК ИДАРӘСЕ

---

ПРИКАЗ
10.12.2015г.

БОЕРЫК
№ 01-05/255-пр

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы Дәүләт техник Күзәтчелеге Идарәсенең 16.04.2015 № 01-05/57-пр боерыгына үзгәрешләр кертү турында

1. Татарстан Республикасы Дәүләт техник Күзәтчелеге Идарәсенең 16.04.2015 № 01-05/57-пр боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктын әлеге редакциядә бәян итәргә:

«Вазыйфалар исемлегенә кертелгән дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләүчеләргә эштән киткәндә 2008 елның 25 декабрендәге “Ришвәтчелеккә каршы көрәш” 273-ФЗ номерлы Федераль Законның 12 статьясы нигезендә каралган чикләүләр, бурычлар һәм җаваплылыкны аңлатырга.»;

Татарстан Республикасы Дәүләт техник Күзәтчелеге Идарәсенең 16.04.2015 № 01-05/57-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре вазыйфа биләгәндә үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы мәгълүмат, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы мәгълүмат бирергә бурычлы булган, биләүләре коррупция куркынычы белән бәйле булган дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген кушымта булып килүче яңа редакциясендә бәян итәргә.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башлык — Р.Р.Зиатдинов

Татарстан Республикасы Дәүләт техник
Күзәтчелеге Идарәсенең 16. 04.2015
№ 01-05/57-пр боерыгы белән расланган
(Татарстан Республикасы Дәүләт техник
күзәтчелеге Идарәсенең 10.12.2015
№ 01-05/255-пр боерыгы редакциясендә)

Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре вазыйфа биләгәндә үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы мәгълүмат, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы мәгълүмат бирергә бурычлы булган, биләүләре коррупция куркынычы белән бәйле булган дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге

1. Вазыйфаларның югары төркеменең "җитәкчеләр" категориясе Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары:

идәрә башлыгы – Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтү баш дәүләт инженеры-инспекторы.

2. Вазыйфаларның төп төркеменең "җитәкчеләр" категориясе Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары:

идәрә башлыгы урынбасары – Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтү баш дәүләт инженеры-инспекторы урынбасары.

3. Вазыйфаларның әйдәүче төркеменең "җитәкчеләр" категориясе Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары:

район, шәһәр бүлеге башлыклары-баш дәүләт техник күзәтү инженер-инспекторлары – 44 вазыйфа;

күзәтчелек һәм автомат рәвештә исәпләү бүлеге башлыгы – дәүләт техник күзәтү инженер-инспекторы;

оештыру эшләре һәм хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгы – дәүләт техник күзәтү инженер-инспекторы;

финанслау, бухгалтерлык исәбе һәм анализлау бүлеге башлыгы – дәүләт техник күзәтү инженер-инспекторы;

дәүләт хезмәте, кадрлар, эш башкару һәм хокукый тәэмин итү бүлекчәсе җитәкчесе – дәүләт техник күзәтү инженер-инспекторы.

4. Вазыйфаларның әйдәүче төркеменең "белгечләр" категориясе Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары:

консультантлар- шәһәр һәм муниципаль районнар буенча баш дәүләт техник күзәтү инженер-инспекторлары урынбасарлары – 3 вазыйфа;

күзәтчелек һәм административ гамәли эш бүлекчәсенең әйдәп баручы киңәшчесе-дәүләт техник күзәтү инженер-инспекторы;

теркәү, автомат рәвештә исәпләү һәм махсус эш бүлекчәсенең әйдәп баручы киңәшчесе – дәүләт техник күзәтү инженер-инспекторы;

матди-техник тәэмин итү бүлекчәсенең әйдәп баручы киңәшчесе – дәүләт техник күзәтү инженер-инспекторы.

5. Вазыйфаларның әйдәүче төркеменең “Тәэмин итүче белгечләр” категориясе Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары:

финанслау, бухгалтерлык исәбе һәм анализлау бүлегенең әйдәп баручы белгече – дәүләт техник күзәтү инженер-инспекторы,

6. Вазыйфаларның өлкән төркеменең “Тәэмин итүче белгечләр” категориясе Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары:

теркәү, автомат рәвештә исәпләү һәм махсус эш бүлекчәсенең I разрядлы өлкән белгече - дәүләт техник күзәтү инженер-инспекторы;

күзәтчелек һәм административ гамәли эш бүлекчәсенең I разрядлы өлкән белгече - дәүләт техник күзәтү инженер-инспекторы,

матди- техник тәэмин итү бүлекчәсенең I разрядлы өлкән белгече - дәүләт инженер-инспекторы- дәүләт техник күзәтү инженер-инспекторы,

финанслау, бухгалтерлык исәбе һәм анализлау бүлегенең I разрядлы өлкән белгече - дәүләт техник күзәтү инженер-инспекторы.